**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«19» июль, 2024 ел № 497

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2024 елның 1 июлендәге 437 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары белән расланган муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу буенча методик тәкъдимнәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 01.07.2024 елның 437 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

п.1. «Күпбалалы гаилә турында» таныклык гамәлдә булу срогы тәмамланган очракта, «Күпбалалы гаилә» ташламалары бирелгәндә (алга таба: ташламалар) «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында ташламалар бирелгәндә, ташламаны раслый торган документлар сыйфатында түбәндәге документларны саный:

- Питрәч муниципаль районында күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге карары;

- гомуми белем бирү оешмасында белем алган балалар укыган урыннан белешмә;

- гаиләнең Россия Федерациясендә гражданлыкны раслый торган барлык әгъзаларына документлар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында www.pestreci.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхисламовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ә. Сөләйманов